**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.10.2017 штп. Балык Бистәсе № 239пи

2017 елга гражданнар кеременең
һәм салым салынырга
тиешле мөлкәт хакының иң
чик күләмнәрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 14,49,50 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 6 пункты, 3,4 өлешләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 6 пункты, 3,5 өлешләре нигезендә», «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең иң чик күрсәткечләрен һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү методикасы белән, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы уставының 46 статьясы белән карар бирәм:

1. 2017 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында Карар кабул итү өчен түбәндәге чик әһәмияттәге билгеләргә:

1.1) гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләме:

ялгыз яшәүче граждан өчен – 1 194 831 сум
ике кешелек гаилә өчен - 1 520 694 сум;
өч кешелек гаилә өчен - 1 955 178 сум;
дүрт кешелек гаилә өчен - 2 606 904 сум;
биш кешелек гаилә өчен - 3 258 630 сум;
алты кешелек гаилә өчен - 3 910 356 сум;
җиде кешедән торган гаилә өчен – 4 562 082 сум;
сигез кешелек гаилә өчен - 5 213 808 сум;

1.2) гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең иң чик күләме:

ялгыз яшәүче граждан өчен - 7549,54 сум;

ике кешелек гаилә өчен - 4804,26 сум;

өч кешелек гаилә өчен - 4117,93 сум.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән иң чик күрсәткечләрне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы авыл җирлекләре территорияләрендә муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куелганда кулланырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Д.Ә. Низамовка йөкләргә.

Җитәкче Р.Х.Хәбибуллин